ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТЭСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБЭН ТЕГЕРМЭНЛЕК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕТИМЕРЛЕКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422670, Балык Бистәсе районы
Югары Тегермәнлек авылы,
Совет урамы,72 «а»
тел.(факс): (884361) 2-80-01

422670, Рыбно-Слободский район
село Верхний Тимерлик,
улица Советская, 72 «а»
ИНН 16340053

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2022 елның 31 гыйнвары | № 1 | Югары Тегермэнлек авылы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Тубән Тегермәнлек авыл җирлегендә җирләү(мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законына, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымта нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм 2022 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Югары Тегермәнлек авылы, Совет урамы, 72а һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә .

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы
ТубэнТегермэнлек
авыл җирлеге башлыгы А.Ш. Альмиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Түбән Тегермәнлек
авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 31 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
кушымта

**2022 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2646,95 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 997,28 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 3320,45 |
| Җәмгысе: | 6964,68 |

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегендә ире (хатыны), якын туганнары, бүтән туганнары яисә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан мәет куюны гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә ала торган башка зат булмаганда, мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез нигездә (бушлай) күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 500 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2146,95 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 997,28 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3320,45 |
| Җәмгысе: | 6964,68 |